ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

22.10.2020 с. Набережные Моркваши 11

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Никольский поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Никольский поселогы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нче елның 14нче ноябренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Никольский поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы:

- Никольский поселогында балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Никольский поселогы, Центральная урамы, 21А йорт адресы буенча 11.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов